МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ул.Казакова, д.9б, п.г.т. Алексеевское, 422900

МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ»

Казаков ур., 9б йорт, Алексеевск ш.т.б., 422900

Телефоны: (84341) 2-47-49, (84341) 2-48-44, E-mail: Roo.Alx@tatar.ru, https://edu.tatar.ru/alekseevo/aleks

01. 03. 2016г № 158

**Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган
“Туган тел” мастер-класс бәйгесе
оештыру комитетына**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
муниципаль бюджетлы белем бирү учреждениесе “Биләр гомуми белем бирү мәктәбе” нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Абрарова Алсу Раиф кызын
тәкъдим итү .**

Абрарова Алсу Раиф кызы 1969 нчы елда Мамадыш районы Шәмәк авылында туа. 1991 нче елда Казан педагогия институтын тәмамлый.

Хезмәт юлын Алексеевск районы Зур Алан мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып башлап җибәрә. 2010 нчы елда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында “Гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыту теориясе һәм методикасы” программасы буенча квалификацияне үзгәртү курслары үтә. 2004 нче елдан башлап хәзерге көнгә кадәр Биләр урта мәктәбендә рус телле балаларга татар теле һәм әдәбияты укыта. Сабыйларга үзенең көчен, тырышлыгын кызганмыйча белем бирә. Гомуми эш стажы 24 ел, Биләр урта мәктәбендә - 11 ел. 2005 елдан югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Алсу Раиф кызы дәресләрендә уен, коммуникатив-үстерелешле, проект технологияләрен уңышлы куллана. Укытучы компьютер технологияләреннән дә оста файдалана. “Коммуникатив үстерелешле укыту технологияләрен кулланып укучыларның танып-белү сәләтен үстерү” - дигән методик тема өстендә эшли.

Алсу Раиф кызы заманча җиһазландырылган татар теле һәм әдәбияты кабинеты җитәкчесе. Кабинетта дәрестә куллану өчен тарату, дидактик материаллары, төрле дәрәҗәдәге биремнәр белән карточкалар, тестлар, күрсәтмә әсбаплар, методик эшкәртмәләр тупланган. Дидактик материаллар, дәрес планнары һәр класс өчен системага салынган. Алсу Раиф кызы методик лабораториясен күрсәтмә материаллар, методик ярдәмлекләр белән даими тулыландырып тора.

Укытучы балалар һәм эти-әниләр белән бергә “Аулак өй”, “Сабантуй”, “Нәүрүз”, “Татар халык ашлары ярминкәсе” кичәләре һәм бәйрәмнәр үткәрә.

Үзенең эш тәҗрибәсен коллегалары белән дә бик теләп уртаклаша. Район татар теле укытучылары өчен 2014 нче елда “Ел фасыллары” (6 сыйныф), 2015 нче елда республикакүләм методик коучингта “Һөнәрләр” (5 сыйныф) темасы буенча ачык дәресләр, 2015 нче елда районның башлангыч сыйныф укытучылары семинарында мастер-класс; “Шүрәледә кунакта”, “Әбиемнең күңел сандыгы” дигән класстан тыш чаралар үткәрде.

2004 нче елдан татар теле һәм әдәбияты укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе булып тора. Республика семинарларында һәм конференцияләрдә “ФДБС шартларында татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә коммуникатив технологияләр кулланып укучыларның иҗади сәләтен үстерү”, “Татар теле укытуда заманча технологияләр”, “Дәреснең технологик картасын төзү” дигән темаларга чыгыш ясады.

2013 нче елда “Фән һәм мәктәп” журналында “Татар теле дәресләрендә укучыларның иҗади сәләтен үстерү” һәм бөтенроссия фәнни-методик конференция материаллары җыентыгында «ФДБС шартларында рус төркемнәрендә татар теле дәресләрендә укучыларның танып белү сәләтен үстерү» темаларына мәкаләләре басылып чыкты.

Алсу Раиф кызы 2013 нче елда “Борынгы Биләр” (“Юность в Древнем Биляре”) республикакүләм фәнни-гамәли конференциясендә укытучылар секциясендә эш тәҗрибәсен уртаклашып беренче урынны алды.

2014 нче елда “Иң яхшы укытучы” ( “Наш лучший учитель”) грантына лаек булды. Аның 9 нчы сыйныфлар өчен төзелгән “Кызыклы грамматика” электив курс программасы КФУ ның “ Татар тел белеме” кафедрасында экспертиза узды.

Соңгы өч еллык нәтиҗәләр буенча татар теленнән белем сыйфаты 51%тан 58%ка, татар әдәбиятыннан 63%тан 69% ка күтәрелде. Өлгереш 100%.

Аның укучыларының уңышлары:

2013 нче елда 11 нче сыйныф укучысы Ильдуганова Мила рус телле балалар өчен татар теленнән район олимпиадасында җиңү яулады һәм республика олимпиадасында катнашты. 2015 нче елда 6 нчы сыйныф укучылары Кузнецова Оксана һәм Рузанова Анна рус телле балалар өчен татар теленнән район олимпиадасында призёр булдылар.

2013 нче елда Әбрар Кәримуллин исемендәге республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә өченче урын;

Салих Сәйдәшев иҗатына багышланган республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә өченче урын;

“Мин авылны сайлыйм” (“Я выбираю село”) республикакүләм фәнни-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләр конкурсында өченче урын;

2014 нче елда:

XII Каюм Насыйри исемендәге төбәкара фәнни-тикшеренү укуларында өченче урын;

XIII Каюм Насыйри исемендәге төбәкара фәнни-тикшеренү укуларында өченче урын;

“Мин –тикшерүче” Идел буе фәнни – гамәли конференциясендә өченче урын ;
Н.И.Лобачевский исемендәге Идел буе фәнни – гамәли конференциясендә кызыксындыру дипломы;
“Яшьләр фәнни эзләнүдә” республикакүләм фәнни-гамәли конференциясендә “Милли сәнгатьне өйрәнүче” номинациясендә лауреат;
Республикакүләм «Туган телем-серле тел» шигырь бәйгесендә беренче һәм өченче урын;

2015 нче елда

«Туган телем-серле тел» шигырь бәйгесендә беренче һәм өченче урын;
Яр Чаллы шәһәрендә үткәрелгән «Сәхнә көзгесе» театраль фестивалендә Алсу Раифовна җитәкләгән театраль коллектив 3 нче урын алды.

Тырыш хезмәте, яшь буынны укыту һәм тәрбияләү өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен 2003 нче елда Алсу Раиф кызы ТР Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы, 2014 нче елда Алексеевск районы Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Алсу Раиф кызы укытучылар коллективында, ата-аналар һәм укучылар каршында үзенең тырыш хезмәте белән зур ихтирам казанды.

Муниципаль казна учреждениесе “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге” эш нәтиҗәләре буенча Абрарова Алсу Раиф кызын ана теле һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” мастер- класс бәйгесендә катнашырга лаек дип таба.

**Мәгариф бүлеге башлыгы** **А.В.Симашева**